ГЛАВА
ЭБАЛАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2019 нчы елның 22 нче ноябре Ябалак авылы № 5

2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлаулары уздыру турында

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «2020 елга һәм 2021-2022 елларга план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге бюджеты проекты турында» карар буенча фикер алышуда катнашуга хокукларын үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Уставына таянып,КАРАР БИРӘМ:

1.2019 елның 13нче ноябрендә мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында халыкка игълан ителгән Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге Советының «2020 елга һәм 2021-2022 елларга Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге бюджеты проекты турында» карары буенча халык тыңлаулары уздырырга.

2.Әлеге карарны җирлекнең мәгълүматый стендларында һәм рәсми сайтында 2019 елның 23 нче ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

3.Билгеләргә:

халык тыңлаулары уздыру вакыты- 30.11.2019 10.00 сәг;

уздыру срогы – 1 көн;

уздыру урыны – ТР, Кайбыч районы, Ябалак авылы, Якты урамы, 4 нче йорт (адресы буенча урнашкан административ бинасында);

халык тыңлауларында фикер алыша торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр, чыгышясап катнашуга заявкалар бирелергә мөмкин адрес: ТР, Кайбыч районы, Ябалак авылы, Якты урамы, 4 нче йорт ( эш көннәрендә - 8.00 - 17.00 сәг кадәр).

4.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлегеБашкарма комитетына2020 елга һәм 2021-2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Ябалак авыл җирлеге бюджеты проекты буенча халык тыңлауларын әзерләргә һәм уздырырга.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуныүз өстемә алам.

Татарстан Республикасы

Кайбыч муниципаль районы

Ябалак авыл җирлеге башлыгы Гыйзәтуллина М. Ф.